**ГЛАВА БОЛЬШЕОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422646, с. Большой Ошняк, ул. Г.Тукая, дом 28а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ӘШНӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422646, Олы Әшнәк, Г.Тукай урамы, 28а нче йорт,

Тел.: (84361) 27738, факс: (84361) 27738, e-mail:Bosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**Олы Әшнәк ав** **№ 2**

**08 ноябрь 2021 ел**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк торак пунктларында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Әшнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2021 елның 22 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2021 елның 22 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы. Әшнәк авыл җирлегенең Кече Әшнәк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2021 елның 22 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Кече Әшнәк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2021 елның 22 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.
5. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген

территориаль билге буенча бүләргә.

6. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авылы су скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру;

- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;

- транспорт хезмәтләре өчен түләү;

- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарының юл йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (урамнарны чистарту);

- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авылы урамнарына энергияне саклый торган лампалар сатып алу;

- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарының читләреннән чүп үләннәре чабу;

- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авылларының су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорт; Кече Әшнәк авылы, Красноармейская урамы, 32а һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда кабул ителү белән 3 көн эчендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге
Башлыгы Р.А.Хөснетдинова